СОВЕТ СУНЬСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Яруллина, д.7а, с. Малая Сунь,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422173

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Яруллин ур., 7а йорт, Кече Сон авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422173

тел.(факс): (85563) 3-07-03; e-mail: Sun.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

**КАРАР** **РЕШЕНИЕ**

**№ 2-36** **от 24 сентября 2018 года**

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Сон авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм аларны куллану буенча җирле референдум үткәрү көнен билгеләү турында

«Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 ел, 12 июнь, 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясының 2 пункты, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 ел, 6 октябрь, 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, "Жирле референдум турында» 2004 ел, 23 март, 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Сон авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 11 статьясы, Сон авыл җирлеге башкарма комитетының "Референдум уздыру инициативасы турында" 2018 нче елның 17 нче сентябрендә кабул ителгән 14 номерлы карары, Сон авыл җирлеге Советының "Референдум уздыру инициативасы турында" 2018 нче елның 17 нче сентябрендә кабул ителгән 6-35 номерлы карары, Сон авыл җирлеге Советының "Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Сон авыл җирлегендә гражданнардан узара салым акчасын җыю һәм куллану кагыйдәләре" 2014 нче елның 2 нче апрелендә кабул ителгән 2-33 номерлы (17.09. 2018 №5-35 редакцисендә) карары нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Сон авыл җирлеге Советы К А Р А Р КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Сон авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм аларны куллану буенча җирле референдум үткәрү көнен 2018 нче елның 18 нче ноябренә билгеләргә.
2. Җирле референдумга чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Сон авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, күп балалы гаиләләр, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия

Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2019 елда 400 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

1. Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмиятле автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеген гамәлгә ашыру:

- Югары Сон торак пунктында М.Җәлил, Г.Тукай, Совет урамнары ягына баручы юлны, Кече Сон торак пунктында Х.Такташ, Гагарин урамнары ягына баручы юлны, Урта Сон торак пунктында Г.Тукай урамына баручы юлны вак таш җәеп ремонтлау;
- авыл җирлегенә караучы юлларны кардан чистарту.

« ӘЙЕ » « ЮК »

2. Әлеге карарны муниципаль берәмлек Советының мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен Мамадыш муниципаль районы Сон авыл җирлеге башлыгы М.Ф.Салаховка йөкләргә.

Мамадыш муниципаль районы
Сон авыл җирлеге башлыгы,
Совет председателе /М.Ф.Салахов/